КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 12 октябрь г.Казань № 1301

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 185 нче; 2022 ел, 9 июль, 659 нчы; 2022 ел, 7 декабрь, 1297 нче; 2023 ел, 11 апрель, 447 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидия бирү турында килешүнең (шартнамәнең) бертип формасы кушымтасында китерелгән форма буенча Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән түбәндәгеләр турында өстәмә килешү төзәргә:

субсидия алучының социаль әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган тиешле чыгымнар күләменә үзгәрешләр кертү һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә төзәтмәләр кертү турында (әлеге Тәртипнең 3.4 пунктындагы егерменче абзацында күрсәтелгән шартлар барлыкка килгән очракта);

Субсидия бирү турында килешүне өзү хакында.»;

3.4 пунктта:

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидиянең максатчан билгеләнешен саклап, өстәмә социаль әһәмиятле чаралар үткәргәндә Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткечен арттыру ягына һәм Субсидия бирү турындагы килешү нигезендә субсидия алучыга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән субсидия акчасы чикләрендә төзәтмәләр керткәндә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешүне өзү субсидия алучының эшчәнлеге үзгәртеп оештырылган яисә туктатылган, субсидия алучы тарафыннан аны биргәндә билгеләнгән субсидия бирү тәртибе һәм шартлары бозылган очракта мөмкин. Министрлык Субсидия бирү турындагы килешүне субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, субсидия алучы һәм Министрлык тарафыннан Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, моңа кадәр Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында килешеп булмаган очракта берьяклы тәртиптә өзәргә мөмкин. Субсидия алучы тарафыннан Субсидия бирү турындагы килешүне бер яклы тәртиптә өзү рөхсәт ителми.»;

3.6 пунктта «акча» сүзен төшереп калдырырга;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – социаль әһәмиятле чараны (чараларны) гамәлгә ашыру срогы тәмамланган датага 100-процент күләмдә үткәрү, чараның төгәл тәмамлану датасы һәм нәтиҗәләрнең (нәтиҗәләрнең конкерт микъдари тасвирнамәсе) соңгы күрсәткечләре Субсидия бирү турындагы килешүдә һәр социаль әһәмиятле чара өчен күрсәтелә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр:

үткәрелгән социаль әһәмиятле чаралар күләме, саны;

социаль әһәмиятле чараларда катнашучылар саны, кеше;

социаль әһәмиятле чараларны гамәлгә ашыру срогын үтәү, көн.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин